وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№7 (104). 30 сентябрь 2011 / 3-зөлкагъдә-1432

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



"Мәчет каршындагы курслар - халыкны иман йортларына җәлеп итүнең нәтиҗәле бер чарасы" ▷2◁



Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата ▷3◁



Очкычтан котым оча... ▷4◁

*1 октябрь - Халыкара өлкәннәр көне*

# ӨЛКӘННӘРНЕ ХӨРМӘТ ИТИК!

***Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә һәрберебезгә дә хәерле көннәр, хәерле тормышлар насыйп итсә иде.***

***Раббыбыз Коръәни-Кәримдә Үзе үк бу дөньяда ничек итеп әҗер-саваплар җыярга мөмкин икәнлеген күрсәтте. Без күп вакытта ниндидер бер эш эшләп, шуның аша Аллаһы Тәгаләгә якынаерга тырышабыз. Ниндидер гамәлләр кылып, әҗер-савап җыябыз. Ә бактың исә, җәннәт - ул аяк астыбызда, дөресрәге, әниләрнең аяк астында. Җәннәткә ирешү өчен без савапны тирә-юнебездән җыярга тиешбез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) вакытында Гали (р.г.) һәм башка сәхабәләрнең олыларга, гомумән, өлкән кешеләргә карата хөрмәт күрсәтүләре бәрабәренә Аллаһы Тәгаләнең җәннәт вәгъдә иткәнлеген беләбез. Олы кешеләрне, иң беренче чиратта, үзеңнең олыгайган әтиәниеңне, туган-тумачаларыңны, күршеләреңне, үзеңнең юлыңда очраган өлкәннәрне ихтирам итсәң, игътибарлылык күрсәтсәң, әлбәттә, Аллаһы Тәгалә синең дәрәҗәңне күтәрер. Гали (р.г.) яһүди картына ихтирамлылык күрсәткәнгә күрә, Аллаһы Тәгалә аны да зурлады. Әҗер-савап алсын өчен иртәнге намазда пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) янына Җәбраил фәрештәне җибәреп, рөкүгътан билен турайтмыйча, аны озак кына торгызды һәм Гали (р.г.) килеп кушылгач кына, намазын дәвам иттертте. Ни өчен болай эшләдең дигәч, ул: "Гали олы кешегә хөрмәт күрсәткәнгә күрә, Аллаһы Тәгалә аңа хөрмәт күрсәтте һәм җәмәгать намазының әҗерен алырга мөмкинлек бирде", - диде. Шулай эшләү бәрабәренә, Аллаһы Тәгалә аны хөрмәтләде.***

***Алай гына да түгел, олы кешеләр инде алар үз тормышларын яшәгәннәр, җәмгыятебездә файдалы эз калдырганнар, шуның өчен Аллаһы Тәгалә каршында өлкәннәр - әлбәттә, хөрмәткә лаеклы кешеләр. Хәтта Аллаһы Тәгалә олы кешене газапларга, аны җәзага тартырга, тәмугка кертергә ояла, ди. Пәгамбәребез (с.г.в.) бер мөбарәк хәдисендә: "Иң бәхетле булганнарыгыз - ул да булса, озын гомерләр кичереп, шул яшәгән тормышыгызда Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылганнарыгыз", - диде. Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә аерым бер көннәрдә генә түгел, һәрдаим өлкәннәребезне хөрмәт итәргә насыйп итсә иде. Чөнки безнең дә олыгаясыбыз бар, бер көн килер, без дә алар кебек олы яшьтә булырбыз, безне дә шулай ихтирам итсеннәр өчен, Аллаһы Тәгалә безгә башка бәндәләрен ихтирам иттерсен өчен, без инде, әлбәттә, пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) сөннәтен үтәп, аларга хәер-хөрмәт күрсәтергә тиеш булырбыз.***

*Үзәкләшкән дини оешма -*
*ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ*



## Рөстәм МИҢНЕХАНОВ: "ИҢ МӨҺИМЕ – МИЛЛӘТАРА ТАТУЛЫКНЫ САКЛАП КАЛУ"

Россиядәге һәр милләткә үз гореф-гадәтләрен тоту мөмкинлеген бирү һәм төрле милләт вәкилләре арасында бер-берсенә карата ихтирам һәм хөрмәт саклап калуның мөһимлелегенә басым ясады "Российская газета. Неделя"га биргән әңгәмәсендә ТР Президенты Р.Миңнеханов.

itar-tass.com агентлыгы хәбәр итүенчә, Рөстәм Миңнеханов: "Россия - күпмилләтле дәүләт, мондагы халыклар гасырлар буе тыныч һәм тату яшәгән һәм алар бер-берсенә ияләшеп беткән дисәң дә була. Шуңа күрә иң мөһиме - моңа кадәр ирешелгәннәрне саклап калу, бер-береңә ихтирамлы мөнәсәбәтләр булдыру, һәр милләткә һәм һәр дингә үз традицияләрен, гореф-гадәтләрен үтәргә мөмкинлек бирү", - дип белдергән.

Татарстан Президенты мәктәпләрдә дин укыту мәсьәләсен дә кузгаткан. "Күз алдына китерик: без балаларга православие динен укыта башлыйбыз, ди. Ә ислам динен кая куячакбыз? Яисә хәрби частьләрне алыйк. Әгәр дә анда чиркәү төзибез икән, аның мәчете дә булырга тиеш, армиядә бит мөселманнар да бар! Димәк, безгә барлык ихтыяҗларны да исәпкә алып, бик сак эш итәргә кирәк", - дип белдергән Рөстәм Нургали улы.

Аның сүзләренчә, дини җирлектә туган низаглардан котылу өчен, хәзер милли балансны саклау үтә дә мөһим. "Әлеге мәсьәләләр гел баш калкытып тормаса да, алар бар. Әгәр дә аңа тиешле игътибар бирмәсәк, вак-төяк ызгышлар җыела барып, киләчәктә шартлауга китерүе мөмкин. Дин белән дә нәкъ шулай ук, - дип аңлатма бирде Р.Миңнеханов. - Россиядә әлеге балансны аеруча сакларга кирәк. Әгәр дә проблемалар килеп туса, сәбәбен диннән яисә милләттән түгел, ә үзеңнән эзләргә кирәк".

"Мин мәчеткә дә, чиркәүгә дә керәм, - дип уртаклашты Татарстан Президенты. - Мин - мөселман һәм мин моны яшермим. Мөселманнарның төрлесе бар - намаз укыганнары һәм укымаганнары. Тик минем көнгә биш вакыт намаз укырга вакытым юк… Ләкин мин гыйбадәт кылучыларны хөрмәт итәм".

"Минем шунысын гына әйтәсем килә: бу - безнең милләтнең дине, - дип белдерде Р.Миңнеханов. - Минем әнием әлеге барлык гореф-гадәтләрне дә таный һәм шулай ук безнең өйдә дә әлеге традицияләрне ихтирам итәләр. Чиркәү дә, мәчет тә булырга тиеш. Ләкин алардан нинди дә булса сәясәт ясарга кирәк түгел".

Татарстан Президенты фикеренчә, дин - кирәкле әйбер, ләкин ул сәяси вәзгыять белән идарә итәргә һәм аңа катышырга тиеш түгел. "Дин белгечләре сәясәт белән шөгыльләнә башласалар да, яхшыга бармас. Чиркәү, мәчет - ул кешеләрнең нинди дә булса проблемаларын чишү урыны түгел, ә аларның рухи хаҗәтләрен канәгатьләндерү өчен", - диде Миңнеханов.

**ISLAMNEWS.RU**

## Разил ВӘЛИЕВ: "КОНСТИТУЦИЯДӘ БАРЛЫК ДИННӘР ДӘ ТИГЕЗ"



***Башкортстан һәм Татарстан парламенты Россия җитәкчелегенә мөрәҗәгать итте: Ураза һәм Корбан бәйрәмнәрен уздыру турындагы мәсьәлә уңай хәл ителергә тиеш. Бу хакта Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев 27 сентябрьдә Казанда беренче тапкыр уздырылган республика мәчетләре мөгаллимнәренең I Киңәшмәсендә белдерде.***

- ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты дин мәсьәләләрен дә карый. "Вөҗдан иреге һәм дини оешмалар хакында", "Татарстандагы истәлекле даталар һәм бәйрәмнәр турында"гы кануннарыбыз бар. Без Россиянең "Вөҗдан иреге һәм дини оешмалар хакында"гы законы белән канәгать түгел. Россия Конституциясендә "барлык диннәр дә тигез", дип язылган. Әмма вөҗдан иреге турындагы законда иң беренче урынга бер генә дин куела. Аерым бер дингә генә өстенлек булырга тиеш түгел. Бу хактагы фикерләребезне әйтеп, Россия Дәүләт Думасына закон проекты әзерләп җибәргән идек. Әмма бүгенге көнгә кадәр безне хупларга җыенмыйлар. Моның белән һич кенә дә килешә алмыйбыз, киләчәктә бу өлкәдә үзебезнең эшебезне дәвам итәргә җыенабыз, - диде Р.Вәлиев.

"Разил әфәнде бу көннәрдә дин әһелләре арасында гына түгел, киң җәмәгатьчелектә дә бәхәсләр уяткан дини бәйрәм көннәрендә ял итүгә кагылышлы Россия Югары суды карары белән килешмәвен әйтте", - дип яза intertat.ru электрон газетасы.

- Без республикабызда моннан дистә ел элек үк Корбан гаетен закон нигезендә ял көне дип билгеләдек. Менә узган ел гына Татарстан Дәүләт Советында яңа закон кабул итеп, Ураза гаетен дә рәсми ял көне, дип игълан иттек. 922 елның 21 маенда Бөек Болгар дәүләтендә ислам диненен рәсми дәүләт дине итү турындагы датаны шулай ук законга кертеп куйдык, - дип искә төшерде ул. - Әмма бу арада куанычлы гамәлләргә тап төшә башлады. Илебезнең Югары суды Россия субъектларының үз бәйрәмнәрен булдыра алулары - законсыз, дигән карар чыгара. Башкортстан һәм Татарстан парламентлары моңа ризасызлык белдереп, Россия җитәкчелегенә мөрәҗәгать итте. Хәзерге вакытта әлеге мәсьәлә карала. Һичшиксез, Россия законына үзгәрешләр кертелергә һәм төбәкләр үзләренең бәйрәмнәре турында законнар кабул итәргә тиеш. Минемчә, бу мәсьәләгә ачыклык керер, ул уңай хәл ителер, дип ышанырга кирәк. Конституцияне бозарга беркемнең дә хакы юк. Президентның да, министрларның да, депутатларның да".

ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиевнең сүзләре Татарстанның төрле районнарыннан җыелган дин әһелләрендә алга таба да дини бәйрәмнәрнең ял көне булып калачагына ышаныч уятты.

# Дөньякүләм танылган татар галимнәре Казанга җыела



***Чит илләрдә яшәүче татар галимнәре ярдәме белән дөньякүләм базарда Татарстан урынын ныгыту мөмкинме? Галим милләттәшләребезнең тарихи Ватаннары - Татарстан белән хезмәттәшлеге ни рәвешле тормышка ашырыла алачак? 30 сентябрьдә Татарстан Фәннәр академиясендә уздырылачак Бөтендөнья татар галимнәре форумының төп бурычы - әнә шул сорауларга җавап табу. Татарстан Фәннәр академиясе оешуга 20 ел тулу уңаеннан үткәрелүче форумны Татарстан Фәннәр академиясе һәм Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты оештыра, - дип хәбәр итә intertat.ru сайты.***

Төрле илләрдә, чит җирләрдә яшәп, зур үрләр яулаган татар галимнәре Казанга беренче тапкыр гына җыелмый инде. Аларның тәүге җыеннары 2007 елда зурлап үткәрелгән иде. Анда 15 илдән ике йөз иллеләп фән эшлеклесе катнашты. I Форумда татар галимнәренең координацион советы төзелде. Нәтиҗәдә, татар галимнәренә кагылышлы мәгълүматлар базасы булдырылды, "Татарстан Республикасы өчен 50 иң яхшы инновацион идея" дип аталган конкурс барлыкка килде.

## Әмма шулай да...

Республикабызның "Татмедиа" матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгында уздырылган журналистлар белән очрашуда Татарстан Фәннәр академиясе җитәкчесе Ә.Мазһаров: "Алга куелган төп максатлар үтәлмәде", - дип белдерде. "Безнең чит илдә яшәүче татар галимнәре уйлап тапкан ысуллар әлегә республикабызда гамәлгә кертелмәде. Әлбәттә, I Форумнан соң узган дүрт ел вакыт күп түгел. Дөнья күләмендә танылган татар галимнәре ярдәме белән Татарстанда иң яхшы химия сәнәгатен (промышленность) булдырырга, машиналар эшләргә, китаплар язарга була иде. Чөнки Татарстан кебек кечкенә республика барлык өлкәләр буенча да беренче булып бетә алмый. Без беркемнән дә ким түгел. Әмма бөтенесен дә үзебез генә ерып чыга алмыйбыз. Галимнәр белән бергә җыелып икътисадыбызны үстерә алырбыз дип уйлыйм, Татарстанда эшләнгән продукция дөньякүләм базарда беренче урында торсын иде", - диде академик Әхмәт әфәнде.

Димәк, алга таба татар фән эшлеклеләрен Казанга китереп берничә көн кунак итү генә түгел, ә аларны даими җәлеп итүнең, үзара хезмәттәшлекнең анык юлларын табу сорала.

Фәннәр академиясе җитәкчесе сүзләренә караганда, аларны күбрәк безнең университетларга чакырып эшләтәсе иде. "Хәзер университетларда андый мөмкинлекләр бар. Мәскәүдә бу эш белән шөгыльләнүче комитет булдырылды, аның әгъзасы - татар галиме. Комитет бик катлаулы экспертиза уздырып кына эшкә чакыра. Монда килеп акча эшләргә теләүчеләр бик күп. Әмма безгә зур уңышларга ирешкән галимнәр кирәк", - диде ул. Ә чит ил галимнәре безгә килергә теләрме соң? "Җан тартмаса да, кан тарта дигәндәй, әлбәттә, киләргә торалар. Алар Казанда берничә ай эшләп китәргә каршы түгел. Форум кысаларында без менә шул элемтәләрне ныгытырбыз", - диде Әхмәт Мазһаров.

Тагын бер мәсьәлә - Татарстан өчен иң яхшы инновацион идеяләргә кагылышлы бәйгене Россия кысаларында гына калдырмыйча, дөньякүләм дәрәҗәдә уздырасы иде. Тик бу теләк, иң беренче чиратта, матди як белән бәйле. Конкурста катнашу, анда үзеңнең дистә елларга сузылган фәнни эшеңнең нәтиҗәсе булган казанышыңны бик очсызга "бүләк итү" - чит илләрдә яшәүчеләрнең тәҗрибәсендә күзәтелми. Чыннан да, илле меңгә бер тапкыр ресторанга кереп чәй эчеп чыга торган Америка профессорының конкурс белән кызыксынуы бик шикле.

"ТР Фәннәр академиясе: тарих һәм бүгенге заман" дип аталган форумга Россия төбәкләреннән 150, чит илләрдән 50 галим киләчәк. Әйтик, Төркиядән Надир Дәүләт, Кытайдан Габдулла Аббас, Америкадан Юлай Шамилоглы, Украинадан Рөстәм Абязов, Ташкенттан Искәндәр Байбәков... Күрше Башкортстаннан - 20, Үзбәкстаннан 12 фән эшлеклесе форумда катнашырга үз теләген белдергән. Шунысын да әйтеп узарга кирәк, катнашучылар арасында милләте буенча бүтән милләттән булып, төрки халыклар тарихын өйрәнеп танылган белгечләр дә бар. Академик Ә.Мазһаров: "Форумга килүчеләр күп төрле темаларга чыгыш ясаячак, татар халкының гуманитар һәм төгәл фәннәре казанышларын барлау өчен зур игътибар биреләчәк", - диде. "Татар галимнәре - сигез миллионлы халык тарихы, мирасы, мәдәнияте, фәненең бер өлеше ул", - дип белдерде академик.

***Айзирәк ГӘРӘЕВА.***

---

## Ризаэддин Фәхреддин кулы куелган шәһадәтнамә табылды



***26 сентябрьдә Бөгелмә районының Кудашев авылы мәчетендә район имам-хатыйбларының чираттагы җыелышы үтте. Биредә имамнардан кала, авыл мөгаллимнәре һәм мәэзиннәре дә катнашты. Киңәшмәдә шулай ук район адиминистрациясе вәкилләре дә бар иде.***

Җыелышта күп кенә сорауларга ачыклык кертелде. Шулай ук Изге Рамазан аена да кыскача йомгак ясалды.

Киңәшмәдән соң килгән кунаклар авылның урта мәктәбендәге музейга юл тотты. Музейга килгән кунаклар җирле мәэзин исеменә 1929 елда мөфти Р.Фәхреддин имзасы куелып бирелгән шәһадәтнамәне дә күреп китте.

**DUMRT.RU**

---

## II Кулаткы укулары узды

***24-25 сентябрь көннәрендә Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районында имам-хатыйб, мәэзин, мәчет каршында дин сабаклары бирүче абыстайлар белән берлектә II Кулаткы укулары оештырылды.***

Конференциянең төп максаты - традицион ислам кануннарын торгызу, борынгыдан килгән гореф-гадәтләребезне, хәнәфи мәзһәбен пропагандалау, мәхәлләләрнең торышы, мөхтәсибләрнең эшчәнлеге белән таныштыру, милли мәсьәләләрне күтәрүдән гыйбарәт иде. Җыен Кулаткы эшчеләр поселыгының Җәмигъ мәчетендә үтте.

Конференциядән тыш Хәбибулла хәзрәт Хансоварның кабере зыярәт ителде, Биләр мәдрәсәсенең филиалы ачылды. 25 сентябрьдә җиде йөзгә якын татар яшәүче Николаевск районы посёлыгындагы тәүге мәчеткә манара куелды.

Үткән чарада Татарстанның Баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге мөдире Вәлиулла хәзрәт Якупов, мөфтиятнең гомуми бүлек мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Россия ислам университеты мөгаллиме Рамил хәзрәт Курамшин, Самара белән Саратовтан, Ульяновск шәһәре һәм өлкәсе администрациясеннән шәрәфле кунаклар, шулай ук Ульяновск өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Сәүбән хәзрәт Сөләйманов катнашты.

Чарада Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз исеменнән II Кулатка укуларын оештыручыларга рәхмәт хатлары һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

**DUMRT.RU**



Илдус хәзрәт ФӘИЗ:

# "Мәчет каршындагы курслар - халыкны иман йортларына җәлеп итүнең нәтиҗәле бер чарасы"

***27 сентябрь көнне Россия ислам университетында беренче тапкыр мәчет каршында дини белем бирүче мөгаллимнәрнең республика киңәшмәсе үтте. Киңәшмәдә катнашучыларның күбесе: "Җыелыш Татарстандагы ислам дине мәгарифе өчен тарихи әһәмияткә ия вакыйга", - дип белдерде.***

Җыен дини белем бирүнең сыйфатын үстерү, конфессия һәм халыкара бердәмлек моделен ныгыту, мөселман уку-укыту берләшмәсен яңарту процессына кертеп җибәрү максатыннан оештырылды.

Киңәшмәдә ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз, Татарстанның Баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы вәкилләре, ТР Президентының Дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Россия ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин, ТР Мәгарифне үстерү институтының милли мәсьәләләр буенча проректоры Рәсимә Шәмсетдинова, Казан федераль (Идел буе) университетеның Педагогика һәм психология институты директоры Айдар Кәлимуллин һ.б. катнашты.

Республикабызның тугыз йөз илле мәчетендә дин укыту курслары эшләп килә. Аларда дәрес бирүче ике йөз кырыклап мөгаллим республика киңәшмәсендә катнашты.

Җыенны Коръәни-Кәримнән сүрә-аятьләр уку белән башлап җибәргәч, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге мөдире Вәлиулла хәзрәт Якупов сүз алды. Ул, республикабызда мөселманнарга дини белем бирүнең нигезендә мәчет каршында эшләп килүче курсларның әһәмиятле роль уйнавын, Татарстанда мондый укуларның беркайчан да туктап тормавы турында мәгълүмат бирде. В.Якупов элекке елларда һөнәри белем бирүгә зур игътибар бирелүен, хәзер исә мәчет каршында эшли торган курсларны үстерү өстендә эшләргә кирәклеген дә билгеләп үтте.

Мөфти Илдус хәзрәт Фәиз исә мәчет каршындагы курсларда, гореф-гадәтләребезне исәпкә алып, тиешле дәрәҗәдә белем (сүз уку-укыту эшчәнлеген Коръән һәм сөннәткә таянып, хәнәфи мәзһәбенә нигезләнеп алып бару хакында бара) бирергә чакырды. Ул шулай ук әлеге курслар халыкны мәчетләргә җәлеп итүнең нәтиҗәле бер чарасы булуына да басым ясап үтте. Вакытын да, сәламәтлеген дә кызганмыйча, мөгалимнәрнең дин гыйлеме бирергә алынуын Илдус хәзрәт "бик зур хезмәт, каһарманлык", дип бәяләде. "Дингә аяк бастырып, нигезне билгели торган урын бу", - диде И.Фәиз.

Татарстан Президентының Дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин үз чыгышында мөфтиятнең төрле юнәлештә, шул исәптән уку-укыту өлкәсендә дә эш алып баруын искәртеп узды. Фәнгә, уку-укытуга әһәмият бирүнең үтә мөһим булуына басым ясады. Марат Илшат улы мәчет каршындагы курсларда мөгаллимнәрнең халык белән эшләвен, күпчелек кешеләрнең Аллаһы Тәгалә сүзләрен беренче тапкыр нәкъ менә шунда ишетүен билгеләп үтте. Мөселман зыялылары тәрбияләүнең башында мәчет каршындагы курслар торуын әйтеп узды.

Депутат Разил Вәлиев исә мәчет каршындагы курсларның белемле имамнар әзерләүдә өлеше зур булуына басым ясады. Ул: "Дини белем бирү системасы тәртипкә салынмаса, нәтиҗә булмаячак", - диде.

РИУ ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин мәчет каршындагы курсларны "дини мәгариф системасының беренче баскычында торучы", дип атады. Аның фикеренчә, әлегә нәтиҗәләр яхшы дип әйтергә әле иртәрәк, эшлисе эшләр байтак. "Моңарчы сез ничек бар, шулай эшләп килдегез. Хәзер исә ярдәм итәрлек кешеләр бар", - дип белдерде ул, көн үзәгендә уку-укыту кулланмалары, дәреслекләр әзерләү мәсьәләсенең дә торуын искәртеп.

Ректор шулай ук мәчет каршындагы курсларда белем бирүчеләр өчен гыйлем эстәү дәресләре оештырырга да мөмкинлек барлыгын хәбәр итте. Ә Вәлиулла хәзрәт исә РИУга укырга керергә чакырды. "Сезнең актив рәвештә, бер юнәлештә эшләвегез безнең өчен мөһим. Изге максатны бергәләп кенә тормышка ашырырга мөмкин", - дип тәмамлады сүзен Рәфыйк Мөхәммәтшин.

Әлеге чарада мәчет каршында дини гыйлем бирүче мөгаллимнәр өчен берьеллык программа да тәкъдим ителде, - дип хәбәр итә tatar-inform.ru сайты.

***Римма ГАТИНА***



5 ОКТЯБРЬ – ХАЛЫКАРА УКЫТУЧЫЛАР КӨНЕ

# Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата

**Болгавыр заман уй-фикерләребезгә, аңыбызга үзгәрешләр кертте: барчасы акча хакында сөйли, хезмәтнең сыйфаты турында гына түгел, үзе турындагы сүзләр дә онытылды. Мөгаен, гадәтсезлеге белән адәм баласын шаккатырган бу дәвер үтәр әле. Тик җәмгыятькә генә чиксез күп төзәлмәс яралар ясалыр, намуслы һәм тыйнак, "якты киләчәк"кә ышанган миллионнарча кешеләрнең язмышлары гына бозылыр. Җитештерү һәм товар ясап чыгару да яңадан җайга салыныр, кешеләр бәйгесе һәм товарлар көндәшлеге, бөлү һәм уңышка ирешү аша юньлерәк тормыш та килер. Әлегә моның кайчан буласын гына әйтүе кыен...**



Болгавыр заман уй-фикерләребезгә, аңыбызга үзгәрешләр кертте: барчасы акча хакында сөйли, хезмәтнең сыйфаты турында гына түгел, үзе турындагы сүзләр дә онытылды. Мөгаен, гадәтсезлеге белән адәм баласын шаккатырган бу дәвер үтәр әле. Тик җәмгыятькә генә чиксез күп төзәлмәс яралар ясалыр, намуслы һәм тыйнак, "якты киләчәк"кә ышанган миллионнарча кешеләрнең язмышлары гына бозылыр. Җитештерү һәм товар ясап чыгару да яңадан җайга салыныр, кешеләр бәйгесе һәм товарлар көндәшлеге, бөлү һәм уңышка ирешү аша юньлерәк тормыш та килер. Әлегә моның кайчан буласын гына әйтүе кыен...

Үсеш принциплары арасында кирәкле һәм җитәрлек шартлар бар. Татар халкының тәрәккыятенә (прогрессына) иң зарури шартлар нәрсәдән гыйбарәт соң?

Кешелек дөньясы туплаган тәҗрибә күрсәткәнчә, бихисап казылма байлыклары (нефть, руда, ташкүмер һ.б.) булган милләт тә бары тик үз хезмәте хисабына гына исән кала һәм тәрәккыят итә. Ләкин "абстракт" хезмәт кенә җитәрлек түгел, җитештерүчәнлекне арттыру өчен төп шартлар да - хезмәтне, конкрет эшне яхшы оештыра алу, теләсә кайсы өлкәдә эшләүченең хезмәте максатлы булу, аны башкарырга теләк, мотивация булу мөһим...

Җитештерүдә һәм кеше эшчәнлегенең аңа бәйле өлкәләрендә элек күз алдына да китермәгән үзгәрешләр бара һәм аларның дөньякүләм тенденцияләре бар. Бүген инде теориядә генә түгел, гамәлдә дә хезмәтнең интеллектуальләшүе, җитештерүнең мәгълүматлашуы, роботлашуы һәм компьютерлашуы бик ачык күзәтелә. Алар, кирәкле һәм җитәрлек шартлар буларак, бүгенге социаль-икътисади прогресс нигезе булып тора. Электроника әле кичә генә фән булса, бүген инде алга киткән илләрдә төп җитештерү чараларының берсенә әверелеп бара: һәр гаиләнең өендә телевизор, суыткыч, микродулкынлы мич, компьютер һ.б. күренеп тора.

Чит илләрдә, мисал өчен, технологик эрага кереп баручы Япониядә "караңгы", ягъни утсыз, яктыртылмаган цехлар һәм заводлар бар. Алар продукцияне кеше катнашыннан башка гына чыгаралар! Мәсәлән, телевизорларны автоматлар, роботлар ясый. Кеше цехка үзеннән сизгеррәк булган һәм детальләрне төгәлрәк эшкәртә алган автоматларның эшен тикшерү өчен генә керә. Анда "агым"га салынып эшләнгән товар күбрәк һәм арзанрак кына түгел, югары сыйфатлы да, дөнья базарында өстен дә булырлык. Ә бу - милләтнең яшәү һәм алга китү шартларының иң мөһиме.

Табигый ки, мондый җитештерүгә тирән белемле кешеләр генә хезмәт күрсәтә. Бу очракта һөнәр төрләре үзгәрәме соң? Әлбәттә, чөнки анда төп һөнәр - көйләүче, кул хезмәте күп кулланылган безнең предприятиеләрдәге кебек токарь һәм слесарь түгел. Алга киткән илләрдә кайсы инженер һөнәрләре киңрәк таралган соң? Проектчы, электроник, диагнозчы, программист һ.б., ягъни күбесенчә яңа технология, ноу-хау (җитештерү сере) белән эш итүчеләр.

Һөнәрләр структурасы үзгәрәме? Әйе, галимнәр әледән-әле яңа технологияләр уйлап таба һәм гамәлгә кертә. Фәнни җитештерү зуррак урын ала барган саен, һөнәрләр исемлеге дә тизрәк үзгәрә. Мәсәлән, алга киткән илләрдә өстенлек иткән, технологик яктан яхшы җиһазланган машина төзү тармагын узган гасырның 60-70 нче елларында ук инде гади токарь, слесарь яки фрезерчы кебек тар профильле эшче канәгатьләндерми башлады. Җитештерү автоматлаша, роботлаша барган саен, оста һәм киң профильле эшчеләр - күптөрле кыру, фрезерлау, револьвер станокларында эшли торган токарь-универсал, электр һәм ацетилен белән, төрткеләп эретеп ябыштыручылар (сварщиклар) күбрәк кирәк була башлады. Конвейерларны, автомат станокларны һ.б. көйләүче киң профильле слесарьларга да ихтыяҗ бик тиз артты. Хәзер инде җитештерү өчен гади техник кына ярамый, оста эшчене алыштырырлык техник кирәк. Шуңа күрә дә санлы программа белән идарә ителгән станоклар янына - эш урыннарына - эшчеләр түгел, күбрәк техниклар, хәтта инженерлар баса. Хезмәтнең интеллектуальләшүе тизләнә. Монысы безнең Казан белән Чаллы заводларында да күренә башлады инде.

Бүген югары җитештерүчәнлекне һәм көндәш булырлык товарларны гади эшче, гади техник, гади инженер түгел, югары дәрәҗәдәге һөнәр иясе (профессионал) гына бирә ала. Димәк, кадрларны әзерләгәндә һөнәрне дөрес сайлау, махсуслашу (специальләшү) төп мәсьәлә булып тора. Демократлашу шартларында идарә итү мәсьәләләре дә һәр кимәлдә (дәүләт белән идарә итүдән алып, эшче яки хезмәткәрләрнең кечкенә төркемнәре белән идарә итүгә кадәр) күпкә катлаулана.

Хәзерге техника һәм технологиянең бүгенге уку йортлары белгечләр әзерләгәнгә караганда тизрәк үзгәрүе, инженер-техник фикернең инженер алган белемнән узып китүе шартларында хезмәткәрләрнең функциональ белемсезлеге күзәтелә. Белем - корал ул. Халык әйтмешли, "корал кемнеке - заман шуныкы". Димәк, өзлексез белем бирү системасын төзү өчен һөнәри белем бирүне тамырдан үзгәртеп корырга кирәк. Ул массакүләм һәм һәр кеше өчен өзлексез булырга тиеш. Хәзер педагогикада "өйрәнүчәнлек" (обучаемость) төшенчәсе бар. Шәхесләренең төп сыйфаты - өйрәнүгә сәләт булган милләт кенә алга чыга алачак. Шуның өчен, шәхеснең фикерләү сәләтен үстерү белән бергә, аның ошбу сәләтен дә тәрбияләргә кирәк.

Бу очракта яшьләрне хезмәткә ничек әзерләргә? Аларны кайсы һөнәрләргә җәлеп итәргә? Токарь яки инженергамы? Сәүдәгәр, коммерсант яки электроник, системачыгамы?.. Ни дә булса эшләү һәм башкарудан тыш, төрлечә тәрбияләнгән кешеләр белән аралашуны, тиз элемтә урнаштыра белүне, әдәпле, инсафлы, шәфкатьле булуны таләп иткән, гел киңәя барган хезмәт күрсәтү өлкәсендә ни эшләргә?

Бәлки, без илебездәге хәл-әхвәлне исәпкә алмыйбыздыр? Әле аны гына түгел, бөтендөнья үсү тенденциясен дә исәпкә алу зарури. Без җәмгыять үзгәрүнең гомуми тенденциясенә дә бәйле. Марксизм тәгълиматы киләчәкне иң күп санлы һәм оешкан эшчеләр сыйныфы белән бәйләп, XIX гасыр азагында һәм XX гасырның өч чирегендә булган хәлне генә чагылдыра алды. Ә безнең гасыр азагында алга киткән илләрнең иҗтимагый структурасы үзгәрде. Мәсәлән, XX гасыр башында АКШның авыл хуҗалыгында кешеләрнең 87 проценты эшләсә, хәзер 5 процент кына. Гасыр урталарында сәнәгатьтә 70 процент халык эшләсә, хәзер исә 15 процентка кимрәк. Кул хезмәте кими барганлыктан, белемнең роле арта. XXI гасырда 75 процент халык тәгълимгә (укуга, өйрәнүгә) тартылачак. Шундый тенденция Россиядә дә күзәтелә. Димәк, тимер, нефть, ташкүмер түгел - интеллект (гакыл, ягъни акыл байлыгы, фикерләү сәләте) һәм технология якын киләчәктә иң зур капитал булачак.

Бүген җәмгыять һәм дәүләт эшмәкәрләрчә булдыклы, кыю, иҗади фикерләүче кешеләргә мохтаҗ. Аларны балачактан, мәктәптә үк тәрбияли башларга кирәк. Бу эш Япониядә, АКШта һәм алга киткән башка илләрдә күптән эшләнә инде. Безгә гади җитәкчеләр, элеккечә оештыручылар түгел, кешеләрнең мәнфәгатен аңлап, аларның күңелен күрә белүче, заманча менеджерлар кирәк. Димәк, хәзерге җәмгыятьне "татар халкын рухи тергезү" кебек гомуми лозунглар түгел, иртәгәге җитештерүнең мәгълүмати технологиясенә, кешеләр белән әдәпле-тәртипле аралашу гадәтенә туры килә торган, шәхеснең рухи һәм акыл сыйфатларын үстерүне күздә тоткан программа кызыксындыра.

Татар милләтенең иртәгә буласы язмышы турында сөйләгәндә аның үсү перспективасы югарыда әйтелгән хезмәт шартлары белән тыгыз бәйләнгән. Шуннан чыгып, Татарстанда шәхеснең нинди сыйфатлары, тәгълимне үстерүнең кайсы юнәлешләре өстен икәнен билгеле алабыз.

***Мирза МӘХМҮТОВ, академик***



# Уңайлы да, сәламәтлеккә дә файдалы...

***Ислам дине кануннары буенча киенүче мөселман хатын-кызлары күп Казанда. Өстенә озын җиңле, итәге аяк йөзеннән булган күлмәк кигән, башына матур яулык бәйләгән хатын-кызны күреп, кайберәүләр сәерсенсә дә, күпләр сокланып карый. Үзем дә "яулыклы" кызлар рәтендә йөргәч, бу карашларны еш тоям.***

Мәдрәсәдә алган дини гыйлемем мине кеше сүзеннән өстен булырга, Коръән кушканча яшәргә, киенергә өйрәтте. Аллаһы Тәгалә "Әгъраф (Пәрдә)" сүрәсенең 26 нчы аятендә болай ди: "И адәм балалары! Без сезгә киемнәр яраттык, ул киемнәр гаурәтләрегезне каплар. Янә мал яраттык һәм дә тәкъвалык киеме бирдек, ул тәкъвалык - саклану киеме хәерледер, ошбу зекер ителгән нәрсәләр Аллаһы Тәгаләнең галәмәтләре, шаять кешеләр вәгазьләнерләр". (Ногмани тәфсиреннән.) Шул рәвешле Ул адәм балаларын сәламәт, бәхетле, гөнаһларсыз яшәргә өнди.

Әбиләребез гомер буе бәйләгән яулыкларны, алар кигән озын күлмәк-итәкләрне бер селтәнүдә салып ташлаган хатын-кызларыбыз - чирләшкә буын тәрбияли түгелме? Яшь әбиләребезнең дә итәкләре - тез астына, җиңнәре беләккә кадәр кыскарды. 60-70 яшьлек апаларның яшьләрдән калышмыйча чәчләренә "химия" ясатып, кыска топик белән чалбар киеп куюын аңлап булмый. Андыйларга мөселманча киемнәрнең, яулыкларның уңайлыгын аңлатасым килә. Хәзер базар-кибетләрдә аптырап, үзеңә яраклы кием эзләп тилмерә торган түгел бит. Бер Казаныбызда гына да зур-зур мөселман киеме кибетләре бар. Бәяләре бераз тешләсә дә, үзеңә ошаганын сайлап алу мөмкинлеге зур. Ә яулык-шарфларның, калфакларның ниндиләре генә юк! Киемеңә карап, төсен сайлап ал гына.

Чәчкә матур причёска ясаган кебек, яулыкларны да төрле ысуллар белән бәйләргә була. Мин үзем яулык бәйләү алымнарын интернет челтәреннән өйрәнәм. Казанда ел да уздырыла торган "Мөселман мода"сын гына карап та, бик күп үрнәк өлгеләр алырга мөмкин. Стилистларның фантазияләре чиксез. Хатын-кызларның матурлык яратуын исәпкә алып тегелгән киемнәр тыйнак та, уңайлы да булырга тиеш икәнлекне онытмасыннар гына.

Ләкин күпме генә тыйнак киенмәсен, мөселман кызы һәрвакыт игътибар үзәгендә кала бирә. Җәмәгать транспортына кердеме, университетка, кибеткә генәме - баштан алып аякка кадәр тикшерүчеләр бар җирдә дә табыла. Күпләр өчен үрнәк саналган мөслимәгә һәрдаим үз-үзен дөрес тотарга, нинди генә очрак булса да, килешле киенгән булырга кирәк. Кызганыч, бер мөселман кешесенә генә карап, ислам дине турында фикер йөртүчеләр җәмгыятьтә аз түгел шул.

Кайберәүләр мөслимәләрнең хәзергечә киенүен "гарәпчә" яисә "төрекчә" дип атый. Ярым-шәрә йөргән кешеләрне күрмәмешкә салышсалар да, капланып йөрүчеләрдән гаеп эзләү - исламча киенеп йөрергә оялган, иманнары зәгыйфь булган кешеләрнең карашыдыр, дип уйлыйм мин. Коръәннең "Нур" сүрәсендә: "Аллаһ мөселман булган хатын-кызларны чәчләрен, муеннарын, беләкләрен, тубыкларын, югары чәлтерләрен, колак-алкаларын, муенга таккан зиннәтләрен һәм беләзекләрен ят ирләргә күрсәтүдән тыйды", - дип әйтелә. Иманнарыбызны ныгытып, тагын бер тапкыр ничек киенергә икәнен искә төшерү зыянга булмас. Дөньяга радиация таралу куркынычы туып торганда бу саклану бигрәк тә мөһим бит.

***Мәрьям АБДУЛЛИНА, КФУ студенты***

# Очкычтан котым оча...



Соңгы арада самолётларның һәлакәткә очравын еш ишетә башладык. Самолётка утырып очу - гомереңне беләә торып куркыныч астына кую түгелме? Авиаһәлакәттә үлгән кеше үз-үзенә кул салучы булып саналмыймы? Мин, гомумән, самолётка утырырга куркам. Бу - табигый күренешме? Куркуың белән көрәшергә кирәкме яисә әлеге хисне хәвеф-хәтәрдән саклаучы Аллаһның бер нигъмәте буларак кабул итәргәме?..

*ДИН БЕЛГЕЧЕ ҖАВАБЫ:*

- Бары тик һәлакәтне алдан белеп, аңлы рәвештә шуңа барсаң гына үз-үзеңә кул салу, дип санала. Иртәме-соңгы үлемгә алып бара торган, әйтик, сәламәтлеккә зыяны булган әйберләрне куллану да шуңа керә. Самолётта очуны берничек тә үз-үзеңә кул салу белән тиңләргә ярамый, чөнки автомобильдә йөргәндә дә юл һәлакәтенә очрау ихтималы бар, алда нәрсә буласын беребез дә белми бит.

Әлбәттә, самолётның төзек булмавы турында белгечләр алдан ук кисәткән булса (әйтик, эксплуатация срогы чыгу, техосмотр үтмәү, йөкне кирәгеннән артык итеп төяү), мондый самолётта очу тыела. Әлеге курку хисенә сез таныш сәбәпләр булганда гына бирелсәгез, ягъни курку юктан гына булмаса, аны Аллаһы Тәгаләнең бер бүләге буларак кабул итәргә бик тә мөмкин.

*ПСИХОЛОГ ФИКЕРЕ:*

- Кызганыч, нинди генә авиаһәлакәт булса да, әлеге хәбәрне массакүләм мәгълүмат чаралары киң яктыртып, милли катастрофа дәрәҗәсенә күтәрә. Шулай да дөньяда көн саен меңләгән кеше вафат була һәм шуларның бик азы гына авиаһәлакәт нәтиҗәсендә теге дөньяга күчә икәнлеген онытмасак иде.

Дөрестән дә, бер кешенең үлеме - үзеннән-үзе зур фаҗига һәм бу хәл еш кына самолётларда очу теләгең сүндерергә мөмкин. Бу очракта курку хисе барлыкка килү дә табигый хәл. Курку кичерү сезнең үзегезгә, кабул ителәсе эшләрегезгә начар тәэсир итүе бар. Әгәр дә курку хисе сезгә һәрдаим тынгылык бирмәсә, комачаулап торса, фобия барлыкка килү дәрәҗәсенә җитсә, бу чакта белгечкә мөрәҗәгать итүегез сорала.

Курку, башка тойгылар кебек үк, сигнал белдерү һәм җайга салу вазифаларын башкара, кешегә ул билгеле бер дәрәҗәдә дуамаллык һәм җавапсызлыктан качу өчен кирәк. Безнең бөтенебез дә нәрсәдән булса да курка, сездә исә әлеге хиснең самолётка утырыр алдыннан тууы бик тә табигый.

Әлеге сорауга рациональ яктан якын килеп карасак, самолёт белән генә түгел, Аллаһ сакласын, машинада яисә башка хәрәкәт итү чаралары белән дә төрле хәвеф-хәтәрләр килеп чыгарга мөмкин. Бәлки бу "салкын" караштыр, ләкин статистика шуны раслый. Шуңа да үзегезнең курку хисегезне котчыкмалы итеп кабул итмәгез һәм бу, нәкъ менә сез әйткәнчә, үз-үзебезне саклар, кайгыртыр өчен бирелгән Аллаһның бер нигъмәте генә.

***Җавап islam.ru сайтыннан алынды***

# ГӘҮҺӘРГӘ ЯРДӘМ ИТИК!

***Гәүһәр Исламова - тумыштан җитди авырулы (Аперт синдромы (акрокраниодисфалангия), психик үсеш һәм сөйләм теле тоткарлануның авыр формасы, беренче дәрәҗә анемия һ.б.) ун яшьлек кыз. Ул шушы кыска гына гомере эчендә унөч операция кичерергә өлгергән. Гәүһәр алда торган дәвалану курслары үтү өчен хәзер дә матди ярдәмгә мохтаҗ.***

Бу көннәрдә генә Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз һәм Диния нәзарәтенең ярдәм күрсәтү һәм хәйрия бүлеге җитәкчесе Гөлнара Садыйкова Г.Исламованың өендә булып кайтты, кызның әнисенә дәвалану өчен кирәкле дарулар, азык-төлек бирделәр.

Илдус хәзрәт авыру кызның өендә Коръән укыды, кызның әнисенә, Аллаһы Тәгаләнең сынауларына сабыр булып, иң кыен чакларда да Аңа мөрәҗәгать итеп, ярдәм-шәфкатен сорарга киңәш бирде.

Әгәр дә сез Гәүһәр Исламованың язмышына битараф түгел икәнсез, матди ярдәм күрсәтү өчен "Зәкят" фондына мөрәҗәгать итә аласыз.

***Аның адресы: 420111 ТР, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт.***

***Тел: +7 (843) 236-46-32, 264-60-08; факс: 236-37-62.***

***Электрон почта адресы: fondzakyat@yandex.ru.***

***Сайт: www.закят.рф.***

**Акчаларны түбәндәге исәп-хисап счётына да күчерергә мөмкин:**

**Получатель: Ислямова Фируза Мингазовна**

**Приволжское ОСБ 6670/0216 г.Казань ул.Карбышева 36/2**

**Банк получателя: отделение "Банк Татарстан" 8610 г.Казань**

**Лицевой счёт: 42307810762215553624/48**

**Р/с: 30301810662000606221**

**Корреспондентский счёт: 30101810600000000603**

**БИК: 049205603**

**ИНН: 7707083893**

**КПП: 165902011**



# Урыныгыз җәннәттә булсын, Зәкиулла хәзрәт!



***26 сентябрь көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы әгъзасы, Нурлат шәһәре һәм районының мактаулы имам-хатыйбы Зәкиулла хәзрәт Әхмәтшин арабыздан китеп барды. Ул - республикабыздагы иң өлкән имамнарның берсе иде.***

Булачак дин әһеле 1927 елның 13 мартында Татарстан Республикасының Аксубай районы Иске Кыязлы авылында дөньяга килә, туган авылында җиде класс белем ала. 1944-1951 елларда хәрби көчләрдә хезмәт итә, Бөек Ватан сугышында катнаша. 1951-1959 елларда тимер юлда баш кондуктор булып эшли. 1959-1969 елларда - Чистайдагы СМУ-21 экспедиторы. 1969-1982 елларда нефть тармагында хезмәт куя, бораулаучы ярдәмчесе була. З.Әхмәтшин 1982 елда лаеклы ялга чыга. 1983 елдан башлап Нурлат шәһәрендәге Тимерьюлчылар мәчете рәисе, ә 1988 елдан әлеге мәчетнең имам-хатыйбы булып эшли. 1994 елдан Зәкиулла хәзрәт Нурлат районы имам-мөхтәсибе итеп сайлана, әлеге вазыйфасында ул 2008 елның 22 маена кадәр хезмәт итте. Ә мәчеттә имам-хатыйб булып хәзрәт 2010 елның апреленә кадәр эшләде, 2010 елның 9 апрелендә аңа Нурлат шәһәре һәм районының мактаулы имам-хатыйбы исеме бирелде.

Нурлат шәһәре һәм районының хәзерге имам-мөхтәсибе Айрат хәзрәт Әюпов Зәкиулла хәзрәт турында менә ниләр сөйләде: "Ул Нурлат шәһәрендәге Тимерьюлчылар мәчетендә егерме ике ел имам-хатыйб, унбиш елдан артык Нурлат һәм Аксубай районнарының имам-мөхтәсибе булып эшләде. Нурлат шәһәрендәге беренче мәчет төзелешенә үзенең зур көчен куйды. Зәкиулла абый Нурлат районының имам-мөхтәсибе булып эшләгән чорда утыздан артык мәчет сафка басты. Зәкиулла Әхмәтшин - районыбызда бармак белән генә санарлык аз калган Бөек Ватан сугышы ветераннарының берсе иде. Хезмәт ветеранына ислам динен үстерүгә керткән хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы һәм Россия Үзәк мөселманнары Диния нәзарәтләре тарафыннан бик күп рәхмәт хатлары, мактау грамоталары белән бүләкләнә".

Быелның 31 маенда ТР мөселманнары Диния нәзарәте Пленумында З.Әхмәтшин мөфтиятнең Аксакаллар шурасы әгъзасы итеп сайлана.

Зәкиулла хәзрәт безнең хәтеребездә ихлас күңелле, гадел, тәҗрибәле имам, һәрчак акыллы киңәшләре белән уртаклашырга әзер торган шәхес булып калыр. Без Аллаһы Тәгаләдән аның барлык гөнаһ, хата-кимчелекләре гафу ителүен сорап дога кылабыз һәм Зәкиулла хәзрәтнең авыр туфрагы җиңел булуын телибез.

# Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 1.10.2011 | 05:17 | 06:45 | 13:02 | 16:19 | 18:20 | 19:47 |
| Якшәмбе | 2.10.2011 | 05:19 | 06:47 | 13:02 | 16:17 | 18:17 | 19:44 |
| Дүшәмбе | 3.10.2011 | 05:21 | 06:49 | 13:02 | 16:15 | 18:15 | 19:42 |
| Сишәмбе | 4.10.2011 | 05:23 | 06:51 | 13:02 | 16:13 | 18:12 | 19:39 |
| Чәршәмбе | 5.10.2011 | 05:26 | 06:52 | 13:02 | 16:10 | 18:10 | 19:36 |
| Пәнҗешәмбе | 6.10.2011 | 05:28 | 06:54 | 13:02 | 16:08 | 18:07 | 19:34 |
| Җомга | 7.10.2011 | 05:30 | 06:56 | 13:02 | 16:06 | 18:04 | 19:31 |

*Мәгълүматлар muslem.ru сайтыннан алынды*

# ГЫЙЛЕМ ӨЙРӘНҮНЕҢ ФАЙДАСЫ

***Солтан Мәхмүд заманында итчеләрдән берәүне солтан янына китерделәр. Бу итче каршына солтан Мәхмүд бер сарык китертте. Әйтте:***

- Әй итче! Бу сарыктан күпме ит булыр, күпме май булыр? - диде.

Итче сарыкны тотып карады да, әйтте:

- Фәләнчә кадәр ит, фәләнчә кадәр май булыр.

Шуннан соң сарыкны суйдылар, итче әйткәнчә булды: бер мыскал артык һәм бер мыскал ким булмады. Солтан моны күреп гаҗәпкә калды. Янә сорады:

- Гыйлемнән берәр нәрсә беләсеңме? Итче:

- Белмимен, - диде. Солтан боерды:

- Бу итчене илтеп асыгыз! - диде.

Асарга алып киттеләр. Юл өстендә әлеге итченең улы очрады, мәктәптән кайтып килә иде. Әйтте:

- Минем атамны кая алып барасыз? - диде.

- Асарга алып барабыз, - диделәр. Улы:

- Гаебе нидер? - дип сорады. Әйттеләр:

- Солтан янында куйның ите һәм мае ничәшәр мыскал икәнен белде. Солтан аннан сорады: "Аллаһы Тәгалә сиңа шулкадәр акылзиһен биргән, Алланы нәрсә белән таныйсың?" - диде. Итче исә: "Танымыйм", - диде. Шул сәбәптән атаңны асарга боерды, - диделәр.

Улы әйтте:

- Атамның гаебе шул гына булса, сез бераз сабыр итеп торыгыз, мин солтанның үзен күрим, - диде.

Барды, солтанга сәлам бирде һәм әйтте:

- Минем атамны ни сәбәптән асарга әмер иттең? - диде.

Солтан:

- Аллаһы Тәгалә шулкадәр фәһем-фирасәт биргән икән үзенә, сарыкның ите-мае күпме икәнен мыскалына кадәр әйтеп бирде. Шул зиһене белән Аллаһы Тәгаләне танымый надан калган, шул сәбәптән астырам, - диде.

Итченең улы әйтте:

- И солтан! - диде. - Бу эштә атам гаепле түгел, аны мәктәпкә бирмәгән бабам гаепледер. Син менә мине күр: мин унике яшьлек сабыймын, гыйлемне миннән сора, шәригатьнең бөтен кануннарын әйтеп бирәм, - диде.

Сорадылар, малай бик күп сорауларга җавап бирде. Солтан гаҗәпләнде, бу малай хакына атасын асылудан коткарды.

Шуның кебек әгәр берәүне теге дөньяда Кыямәт көнендә тәмугка китерсәләр, әгәр ул дөньяда булганда улын мәктәпкә укырга биргән булса, улы тәмуг юлына чыгып һәм каршы барып, Аллаһы Тәгаләдән үтенеп, атасын коткарып калыр.

Бу хикәяттән гыйбрәт шул: гыйлем өйрәнү өчен баланы мәктәп-мәдрәсәгә бирү тиешле. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) болай дигән: "Та-ләбү-л-гыйлмә фарыйзәтү галә көллин мөслимин вә мөслимәтин", ягъни "Гыйлем өйрәнү - мөселман ир-егетләренә дә, мөслимәләргә дә тиешле эштер".

**"Гыйбрәтле хикәятләр" китабыннан алынды**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №7 (104) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер-верстка:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-507
**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Бастыруга кул куелды: 29 сентябрь, 14.00 сәгать.**
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**